БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«05» 06 2021 ел

**КАРАР**

№ 187

**Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү хакында**

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

Балтач район башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, «Хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Балтач район башкарма комитетында билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2019 елның 4 декабрендәге 367 номерлы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган вазыйфалар исемлегендә каралмаган Балтач район башкарма комитетында муниципаль хезмәт биләүчеләр, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче гражданнар 2021 елның 30 июненә кадәр «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла торган белешмәләр белән бергә «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 1 нче кушымтасы нигезендә үзләренең иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының цифрлы финанс активлары турында, бер үк вакытта цифрлы финанс активларын һәм башка цифрлы хокукларны үз эченә алучы цифрлы хокуклар турында, утилитар цифрлы

хокуклар һәм цифрлы валюта (алар булса) турында хәбәрнамәләр тапшыралар дип билгеләргә.

2. «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указында каралган хәбәрнамә тиешле вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына тапшырыла.

3. Әлеге карар имза куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.С. Галимуллин